**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Кармыш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**
**«Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең**
**Кармыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**
**турында»**

15 октябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 15 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегең Кармыш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан, I төркем инвалидлардан, өлкән яштәге ялгыз гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, триммерлар сатып алу, триммер өчен бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, торак пунктта хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (Кармыш торак пунктында «ТАШ КАЗАН» иҗтимагый киңлеге территориясен төзекләндерүгә финанслашу, проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) урам күрсәткечләрен (табличкаларын) һәм йорт номерларын ясау, Кармыш торак пунктында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, алыштыру, Кармыш торак пунктында урамнарны яктырту өчен кулланыла торган

электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**- коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны карап тоту, урналар кую, агачларны кисү, казып чыгару, корыган агачлардан чистарту, чүп үләннәрне һәм куакларны бетерү өчен гербицид сатып алу, инвентарь сатып алу, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Кармыш торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар;

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау** (Кармыш торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 216 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 110 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 110 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлегенең Кармыш торак пунктында 2025 елның 15 октябрендәге гражданнар җыеннары карарына үзгәрешләр кертү турында» гы мәсьәлә белән гражданнар җыенын **булып узган, гражданнар җыеннары нәтиҗәләре-чын дип танырга.**

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «Гражданнарга үзара салым кертүгә 2025 елның 15 октябрендә узган гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә, 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең Кармыш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, триммерлар сатып алу, триммер өчен бензин, триммер өчен

запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, торак пунктта хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Кармыш торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны карап тоту, урналар кую, агачларны кисү, казып чыгару, корыган агачлардан чистарту, чүп үләннәрне һәм куакларны бетерү өчен гербицид сатып алу, инвентарь сатып алу, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Кармыш торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар;

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау** (Кармыш торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу) **карар кабул ителгән дип танырга.**

3. Җыен нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Кармыш авылы, Бари Габдрахманов ур., 44А йорты, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гатина